# КАРАР

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Бутлеровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Юеш Көрнәле авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2024 елның 17 октябрендәге 1 номерлы

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 17 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде. «Сез,Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлек студентларыннан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш,2025 елда 500 сум күләмндә үзара салым кертүгә ризамы һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә,түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 516 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар, җыенында катнашучылар саны 271 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Яклыйм» позициясе өчен гражданнар җыенының 270 катнашучысы тавыш бирде;

җыенда 1 катнашучы «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының « Бутлеровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Юеш Көрнәле авыл торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. «Сез,Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән

балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлек студентларыннан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш ,2025 елда 500 сум күләмндә үзара салым кертүгә ризамы һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә,түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә :

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт территориясен төзекләндерү;

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;-сораулары буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Бутлеровка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr:// pravo. tatarstan.ru)бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы** **И.Л. Хушанова**